СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ГОРОД АГРЫЗ» АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ӘГЕРҖЕ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

27.12.2019 Әгерҗе ш. № 38-2

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 2 һәм 28 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 30 октябрендәге 387-ФЗ номерлы Федераль закон, «Гавами тыңлаулар, җәмәгать фикер алышулар оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының 2018 елның 19 июнендәге 23-2 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр проектын беренче укылышта кабул итәргә (1 нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм гражданнарның фикер алышуда катнашу тәртибен расларга (2 нче кушымта).

3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү буенча проектка тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертү буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибен расларга (2 нче кушымта).

4.Гражданнарның «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр проектына тәкъдимнәре «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының законлылык һәм регламенты буенча даими комиссиягә, авторның Ф.И.О. , туган елы, адресын күрсәтеп язмача шушы адреска җибәрелә дип билгеләргә: Татарстан Республикасы, Әгерҗе ш., Гагарин ур., 13, 7 каб. 2 (2 нче кушымта).

5. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Әгерҗе шәһәре” муниципаль берәмлеге Уставында үзгәрешләр проектында чыгышлар хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга заявкалар түбәндәге адрес буенча бирелә: Татарстан Республикасы, Әгерҗе шәһәре, Гагарин урамы, 13, 7 каб. адресы буенча, шәхсән яисә почта аша (конвертка “Устав турында фикер алышу” тамгасын куеп) (3 нче кушымта).

6. «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының утырышлар залында 2020 елның 14 февраленә 14.00 сәгатьтә гавами тыңлаулар билгеләргә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырып, игълан итәргә.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Әгерҗе шәһәре” муниципаль берәмлеге Советы рәисе урынбасары И.Э.Шәймөхәммәтовка йөкләргә.

Совет Рәисе В.В. МАКАРОВ

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 27 декабрендәге 38-2 номерлы карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр проекты

1. 6 статьяның 1 өлешендәге 22 пунктында «территория, бирү» сүзләреннән соң «җирлек чикләрендә урнашкан җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы» сүзләрен өстәргә;

2. 29 статьяда:

2.1. 6 өлештә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда башкасы каралмаган булса» сүзләрен өстәргә;

2.2. 8 өлештә «депутат» сүзеннән соң «күрсәтелгән затларга карата җирле үзидарә органына башка җаваплылык чараларын куллану» сүзләрен өстәргә;

2.3. түбәндәге эчтәлекле 8.1. һәм 8.2 өлешләр өстәргә:

«8.1. Үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында төгәл булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган депутатка, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, әгәр бу белешмәләрне бозып күрсәтү җитди булмаса, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин:

1) кисәтү;

2) депутатны, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасын муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфадан азат итү, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында аның вәкаләтләре вакыты беткәнче вазыйфа биләүдән мәхрүм итү

3) даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан аның вәкаләтләре чоры туктатылганчы даими нигездә вәкаләтләр башкару хокукыннан азат итү;

4) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында аның вәкаләтләре чоры туктатылганчы вазыйфаларны биләүне тыю;

5) вәкаләтләре чоры туктатылганчы даими нигездә вәкаләтләр башкаруны тыю.

8.2. Әлеге статьяның 8.1 өлешендә күрсәтелгән җаваплылык чараларын депутатка куллану турында карар кабул итү тәртибе Татарстан Республикасы законы нигезендә муниципаль хокукый акт белән билгеләнә.».

3. 22 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге статьяда каралган гражданнарның җыены анда сайлау хокукына ия торак пунктта яисә җирлектә яшәүчеләрнең яртысыннан күбрәге катнашканда хокуклы. Торак пунктта әлеге торак пунктта яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия яртысыннан артыгының бер үк вакытта бергә булу мөмкинлеге булмаган очракта, составына күрсәтелгән торак пункт кергән муниципаль берәмлек уставы нигезендә гражданнар җыены гражданнар җыенын үткәрү турында карар кабул ителгән көннән бер айдан да артмаган срокта этаплап уздырыла. Шул ук вакытта элек гражданнар җыенында катнашкан затлар тавыш бирүдә катнашуның алдагы этапларында катнашмыйлар. Гражданнар җыенының карары гражданнар җыенында катнашучыларның яртысыннан артыгы аның өчен тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.».

4. 48 статьяның 1 өлешендәге 3 пунктының өченче абзацында «бирелә» сүзләреннән соң «җирлек чикләрендә урнашкан җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы,» сүзләрен өстәргә.